**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава**
**Какре-Елгинского**
**сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

423320 с.Какре-Елга
ул..Советская, 22,
Тел. 37-0-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Кәкре-Елга авыл җирлеге**
**башлыгы**

Кэкре-Елга авылы, 423320
Совет урамы, 22,
Тел. 37-0-49

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от «19» октябрь 2020 г. № 5

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Кәкре Елга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 30 нче октябренэ билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Якты Юл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум куләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Кәкре Елга авылы Яшьләр урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);;

- Кәкре Елга авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);;

- Кәкре Елга авылында юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Кәкре Елга авылында «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне» һәм « Яңа ел» бәйрәмен оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Кәкре Елга авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Кәкре Елга авылында янгын сүндерү автомобилен карап тоту (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәт хакы, янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр сатып алу);

- Кәкре Елга авылында янгын техникасы өчен янгын гидранты урнаштыру;

Кәкре Елга урамнарының исемнәре язылган табличкалар сатып алу һәм урнаштыру,

-Кәкре Елга авылы территориясендә үләнне җәй көне чаптыру (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.




И.М.Мухаметзянов

Башлык